БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

ПӘНҖЕШӘМБЕ
18 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 90 (5890)
Аерым номеры 10 тиен

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

ҮТӘЛҮНЕ ТИКШЕРҮ— ПАРТИЯ ЭШЕНЕҢ НИГЕЗЕ

Партия оешмаларында булып үткән отчет-сайлау җыелышларында коммунистлар үтәлүне тикшерү эшләренә гаять зур әһәмият бирделәр. Бу бик аңлаешлы. Чөнки үтәлүне тикшерү эшләрен чын магнәсе белән тормышка ашырмый торып, оештыру эшләрен бүгенге политик бурычлар югарылыгына күтәрми торып, нинди дә булса җидди уңышларга ирешү мөмкин түгел. Партия һәм политик эшнең күп еллык тәҗрибәсе белән расланган бу хәкыйкәтне коммунистлар яхшы беләләр.

Бик күп һәм бик яхшы карарлар, приказлар чыгарырга мөмкин. Ләкин әгәр дә бу карарлар һәм приказлар массага үз вактында җиткерелмәсәләр, аларның үтәлеше системалы рәвештә тикшерелеп торылмаса, ул вакытта мондый карарларның һәм приказларның кәгазь волокитасы гына булып калулары мөмкин. Менә шуна күрә дә ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин үзе үтәлүне тикшерү эшләренә зур әһәмият бирәләр һәм бу эшне ничек тормышка ашырырга кирәклекнең гүзәл үрнәкләрен күрсәтәләр.

Партия оешмаларында булып үткән отчет-сайлау җыелышларыннан соң ВКП(б) ның күп кенә башлангыч оешмалары һәм район комитетлары эшнең бу тармагында—үтәлүне тикшерү эшләрен тормышка ашыру өлкәсендә системалы эш алып бара башладылар. Мәсәлән, отчет-сайлауларга кадәр Чистайның судноларга ремонт ясау заводы янындагы партоешмада һәм Серго Орджоникидзе исемендәге завод партоешмасында үтәлүне тикшерү эшләре онтылган участкы булып исәпләнә иде. Хәзер без бу оешмаларда үтәлүне тикшерү эшләренең шактый яхшырганлыгын һәм шуның нәтиҗәсе буларак, көндәлек эштә сизелерлек борылыш ясалуны күрәбез. Судноларга ремонт ясау заводы янындагы партоешма җитәкчеләре производство мәсьәләләре буенча һәм партиянең эчке эшләре буенча эшлекле карарлар чыгарып кына калмыйлар, бәлки ул карарларның ничек үтәлүләрен дә системалы рәвештә тикшереп торалар, карарларны тормышка ашыру буенча завод һәм цех җитәкчеләренә практик булышлык оештыралар. Бу исә производствода эшнең яхшыруын тәэмин итә, җитәкче кадрларда җаваплылык хисе тәрбияли, партия оешмасының авторитетын күтәрә.

Серго Орджоникидзе исемендәге завод парткомы да соңгы вакытта үтәлүне тикшерү эшләренә җидди әһәмият бирә башлады. Бу эш, теге яисә бу карарның ничек үтәлүе турында докладлар тыңлау тәртибендә яки урыннарга барып тикшерү юлы белән алып барыла. Биредә дә нәтиҗә начар түгел, заводта партия-политик эш туктаусыз көчәя бара, коммунистларның авангардлык рольләре күтәрелә.

Соңгы вакытта үтәлүне тикшерү эшләрен сизелерлек дәрәҗәдә яхшырткан партоешмаларны башка предприятиеләр һәм колхозлар буенча да күпләп китерергә мөмкин. Ләкин шулай да бу эш барлык урыннарда да яхшы тора дип булмый әле. Кайбер партоешмалар һәм хуҗалык җитәкчеләре үтәлүне тикшерү эшләренең әһәмиятенә әле һаман да җидди игтибар биреп җиткермиләр. Алар үзләренең бурычлары җыелыш һәм утырыш саен карарлар чыгарудан һәм әледән-әле приказлар биреп торудан гыйбарәт дип исәплиләр. Ә чыгарылган карарларның, приказларның үтәлеше ничек тора, җитәкче оешмаларның директиваларын түбәнге оешмалар ничек үтиләр? Бу нәрсә аларны кызыксындырмый. Шуның нәтиҗәсендә, еш кына хәлләрдә, партия һәм хөкүмәт карарларының үз вактында үтәлмәүләре килеп туа, җитешсезлекләрнең киңәюенә юл куела. Бу инде, үз чиратында, дәүләт планнарының үтәлмәвенә алып килә.

Фактлар өчен ерак барасы юк. Казан тимер юлы идарәсе һәм 3 нче номерлы фанера заводы җитәкчеләренең эш стильләре моны ачык күрсәтә. Казан тимер юлы идарәсе начальнигы Пичугин һәм политбүлек начальнигы Мандур иптәшләр бик күп приказлар һәм директивалар бирәләр. Мәсәлән, Казан тимер юлында аварияләргә һәм крушениеләргә каршы көрәш турында, шулай ук урыннарда техника укуларын юлга салу турында 1940 нчы елның беренче кварталында гына да дүрт приказ чыгарылган. Бу приказларның барсы да бер үк нәрсә турында сөйлиләр. Ләкин аларны үтәү эше оештырылмаганлыктан, приказлар приказ килеш калып киләләр, ә аварияләр саны арта бара.

3 нче номерлы фанера заводы җитәкчеләренә карата да шуны ук әйтергә кирәк. Заводта план үтәлешен тәэмин итәргә кирәклек турында партоешма җитәкчеләре күп сөйлиләр, җыелышларда бер-бер артлы карарлар чыгаралар, завод директоры иптәш Зарифуллин приказлар чыгару буенча да саранлык күрсәтми. Ләкин, карарларны һәм приказларны үтәү эшен оештыру белән партбюро секретаре Шишкин иптәш тә, завод директоры Зарифуллин иптәш тә кирәгенчә шөгыльләнмиләр. Производство мәсьәләләренә карата партоешма һәм дирекция тарафыннан чыгарылган карарларның, приказларның кайберләре хәтта киң массага җиткерелми дә кала. Шулай булгач 3 нче фанер заводында промфинпланның айдан-айга үтәлмичә килүе гаҗәпмени.

Безнең җитәкчеләребез аңларга тиешләр, эшнең нигезе, большевистик җитәкчелекнең аслы бер-бер артлы карарлар кабул итүдә түгел, күп санлы приказлар чыгаруда түгел, бәлки үтәлешне тикшерү эшләрен системалы рәвештә алып баруда, карарларны һәм приказларны ничек үз вактында яхшы итеп үтәргә кирәклеккә кешеләрне өйрәтүдә, партия һәм хөкүмәт карарларына, директиваларына карата җаваплылык хисе тәрбияләүдә. Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин безне болай дип өйрәтә:

„Җиңү бер вакытта да үзе килми,—аны гадәттә тартып китерәләр. Партиянең төп линиясен яклаган яхшы резолюцияләр һәм декларацияләр — болар эшнең башлангычы гына, чөнки болар җиңүнең үзе дигән сүз түгел, бәлки җиңәргә теләү генә дигән сүз. Дөрес линия бирелгәннән соң, мәсьәләнең дөрес хәл ителеше бирелгәннән соң, эшнең уңышы—оештыру эшенә, партия линиясен үткәрү өчен көрәш алып баруны оештыруга, кешеләрне дөрес сайлап алуга, җитәкче органнарның карарларын үтәүне тикшерүгә бәйләнгән". Партия оешмалары һәм хуҗалык органнары җитәкчеләре, эшне әнә шулай оештырырга, яңа җиңүләрне яулап алуның Сталинчыл стилен үзләренә төп сыйфат итеп үзләштерергә тиешләр. Бу стиль—карарларның үтәлешен системалы рәвештә тикшереп торудан һәм аларның тулы үтәлүен тәэмин итүдән гыйбарәт.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Иптәш В. А. Малышевны СССР Халык Комиссарлары Советы Председателенең урынбасары итеп билгеләү турында

Иптәш Вячеслав Александрович Малышевны СССР авыр машина төзелеше Халык Комиссары хезмәтләреннән азат итеп, аны СССР Халык Комиссарлары Советы Председателенең урынбасары итеп билгеләргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
17 апрель, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Иптәш М. Г. Первухинны СССР Халык Комиссарлары Советы Председателенең урынбасары итеп билгеләү турында

Иптәш Михаил Георгиевич Первухинны СССР электр станцияләре һәм электр промышленносте Халык Комиссары хезмәтләреннән азат итмичә, аны СССР Халык Комиссарлары Советы Председателенең урынбасары итеп билгеләргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
17 апрель, 1940 ел.

КОЛХОЗЛАРНЫҢ, КОЛХОЗЧЫЛАРНЫҢ ҺӘМ ЯЛГЫЗ ХУҖАЛЫКЛАРНЫҢ ДӘҮЛӘТКӘ МӘҖБҮРИ РӘВЕШТӘ БӘРӘҢГЕ ТАПШЫРУЛАРЫ ТУРЫНДА

ССР СОЮЗЫ ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫ ҺӘМ ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ КАРАРЫ

Бәрәңге утыртуны тагын да алга җибәрү һәм аның уңышын күтәрү теләге белән, шулай ук шәһәрләрне һәм бәрәңге эшкәртүче предприятиеләрне бәрәңге белән тәэмин итү теләге белән ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карар бирәләр:

1. Колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшырулары бәрәңге утырту планы буенча исәпләүдән гыйбарәт булган хәзерге тәртипне бетерергә.

2. 1940 нчы елгы уңыштан башлап колхозлардан дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңге колхозларга беркетелгән сөрү җирләренең һәрбер гектары исәбеннән тапшырыла дип билгеләргә. Бу тапшырулар „Колхозларның һәм ялгыз хуҗалыкларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык һәм дөге тапшырулары турында" СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1940 нчы ел 11 нче апрель карарының 2 нче статьясе буенча исәпләнә.

3. Союзный һәм автономияле республикаларның халык комиссарлары советларын, край һәм өлкә башкарма комитетларын, ВКП(б) Өлкә Комитетларын һәм край комитетларын һәм союзный республикалардагы компартияләрнең үзәк комитетларын,—дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшыру буенча өлкә, край, республика өчен билгеләнгән нормаларга туры китереп,—дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшыру буенча районнар өчен еллык нормалар билгеләргә һәм СССР Совнаркомы янындагы Экономсовет тарафыннан расланганнан соң аларны көньяк районнар буенча 1940 нчы елның 20 нче маена һәм башка районнар буенча 1940 нчы елның 1 нче июненә игълан итәргә мәҗбүр итәргә.

Дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшыру буенча районнар өчен нормалар билгеләгәндә түбәндәгеләр күздә тотарга:

а) МТС лар хезмәт күрсәтми торган колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшырулары нормаларын бәрәңге буенча шул районда МТС лар хезмәт күрсәтә торган колхозлар өчен билгеләнгән нормалардан 15 процент артык итеп билгеләргә;

б) шәһәрләргә, промышленность үзәкләренә, станцияләргә, пристаньнәргә һәм бәрәңге эшкәртүче предприятиеләргә завод зоналарына якын булган районнарга бәрәңге тапшыру нормаларын арттыру;

в) бәрәңгене куллану урнына китерү кыен булган ерак районнарны дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшырудан бөтенләй яки бер кадәр азат итү;

г) мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык һәм дөге тапшыру буенча районнар өчен нормаларны исәпләгәндә,—дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшыру буенча кимителгән яки күтәренке нормалар алган районнар өчен бөртекле ашлык һәм дөге тапшыру нормаларын тиешенчә арттыру яки киметү.

Дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшыру буенча СССР Совнаркомы янындагы Экономсовет тарафыннан районнар өчен расланган еллык нормалар, кагыйдә буларак, районның барлык колхозларына, колхозчы йортларына һәм ялгыз хуҗалыкларга карата кулланыла. Аерым колхозлар өчен, СССР Хәзерләүләр Наркоматының, край һәм өлкәләргә бүленмәгән республикаларда уполномоченныйларының расламасы белән, дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшыру буенча районнар өчен еллык нормалы 30 процентка кадәр булган чикләрдә арттыруга яки киметүгә юл куярга, ләкин мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшыру буенча гомумән бөтен район өчен булган нормалар шул район өчен расланган нормага бик нык туры килерлек булырга тиеш.

4. Колхозларда бәрәңгенең чынлыкта күпме утыртылган булуына карамастан, колхозларның дәүләткә бәрәңге тапшырулары шушы карарның 2 нче пункты нигезендә сөрү җирләре буенча исәпләнгән күләмнәре үзгәртелмичә кала дип билгеләргә.

5. 1940 нчы елгы уңыштан башлап колхозчы йортларының һәм ялгыз хуҗалыкларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшырулары буенча, бәрәңге утырту мәйданнарының һәрбер гектары исәбеннән, өлкәләр, крайлар һәм республикалар өчен түбәндәге уртача нормаларны билгеләргә:

Өлкәләр, крайлар һәм республикалар	Колхозчы йортлары	Ялгыз хуҗалыклар
Алтай крае	8	12
Архангельск өлкәсе	8	12
Вологда өлкәсе	9	13
Воронеж өлкәсе	8	13
Горький өлкәсе	13	18
Иваново өлкәсе	14	21
Иркутск өлкәсе	10	12
Калинин өлкәсе	12	16
Киров өлкәсе	11	17
Краснодар крае	11	15
Куйбышев өлкәсе	10	15
Курск өлкәсе	9	15
Киров өлкәсе	9	14
Красноярск крае	19	24
Ленинград өлкәсе	15	20
Молотов өлкәсе	20	25
Москва өлкәсе	20	25
Мурманск өлкәсе	2	3
Новосибирск өлкәсе	11	17
Омск өлкәсе	11	19
Орджоникидзе крае	6	8
Орел өлкәсе	15	23
Пенза өлкәсе	12	16
Приморье крае	13	20

Өлкәләр, крайлар һәм республикалар	Колхозчы йортлары	Ялгыз хуҗалыклар
Ростов өлкәсе	6	15
Рязань өлкәсе	15	22
Саратов өлкәсе	9	15
Сталинград өлкәсе	8	14
Свердловск өлкәсе	15	20
Смоленск өлкәсе	12	19
Тамбов өлкәсе	11	17
Тула өлкәсе	17	24
Хабаровск крае	13	20
Чиләбе өлкәсе	14	20
Чита өлкәсе	10	18
Чкалов өлкәсе	8	15
Ярославль өлкәсе	14	16
Башкыртстан АССР	14	19
Бурят-Монголия АССР	6	11
Дагстан АССР	8	10
Кабардино-Балкария АССР	14	25
Калмык АССР	5	8
Карел-Фин ССР	7	11
Коми АССР	11	14
Кырым АССР	8	11
Мари АССР	9	11
Мордовия АССР	15	19
Волга буе немецләре АССР	5	8
Төньяк Осетия АССР	20	25
Татарстан АССР	13	16
Удмуртия АССР	8	16
Чечен-Ингушия АССР	17	22
Чувашстан АССР	9	13
Якутия АССР	6	11
Украина ССР	8	14
Белоруссия ССР	12	20
Азербәйҗан ССР	10	13
Грузия ССР	9	11
Әрмәнстан ССР	9	13
Төркмәнстан ССР	12	16
Үзбәкстан ССР	13	17
Таҗикстан ССР	12	16
Казагстан ССР	9	13
Кыргызстан ССР	13	17

Утыртылган бәрәңгеләре булган эшчеләр, хезмәткәрләр һәм кооперативлашкан кустарьлар дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңгене чынлыкта булган мәйданнан, шул районлагы колхозчы йортлары өчен билгеләнгән нормалар буенча тапшыралар.

6. Дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшыру буенча еллык йөкләмәләрне үтәү өчен, еллык планга карата процентлар белән, түбәндәге календарь срокларны билгеләргә: Архангельск, Вологда, Иркутск, Киров, Молотов, Мурманск, Новосибирск, Омск, Свердловск, Чиләбе һәм Чита өлкәләре; Алтай, Красноярск, Приморье һәм Хабаровск крайлары; Бурят-Монголия, Якутия һәм Коми АССР лар һәм Карел-Фин ССР өчен: сентябрьдә 40 процент, октябрьдә 60 процент, ә барлык калган өлкәләр, крайлар һәм республикалар өчен түбәндәге календарь срокларны билгеләргә: августта 5 процент, сентябрьдә 40 процент, октябрьдә 55 процент.

7. Дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшыруга түбәндәгеләр тартылмыйлар дип билгеләргә:

а) картаю сәбәпле,—ирләр 60 яшькә һәм хатын-кызлар 55 яшькә җиткән булу сәбәпле хезмәткә яраксыз булган кешеләрнең хуҗалыклары,—әгәр аларның шул хуҗалыкта эшләүче, хезмәткә яраклы семья членнары булмаса, шулай ук үзләренең уллары действительный гаскәри хезмәттә булган, ә семьяләрендә 7 яшькә кадәр балалары белән хатыннары калган, картайган ирләрнең һәм хатын-кызларның хуҗалыклары;

б) кызыл армеецләрнең хуҗалыклары,—әгәр дә семья башлыгы действительный гаскәри хезмәттә булса, ә семьядә 7 яшькә кадәр булган балалары белән хатыны калган булса;

в) социаль тәэминат һәм социаль страхование органнары тарафыннан беренче һәм икенче инвалидлык группаларына кертелгән сугыш һәм хезмәт инвалидларының хуҗалыклары.

8. Каралты тирәсе бакчаларында һәм уйсулык урыннарда киндер чәчкән һәм киндер чәчелгән гектарлар саны күләменә карата дәүләткә сүс тапшыру буенча контрактация договорлары нигезендә үзләренең йөкләмәләрен үтәгән колхозларны, колхозчы йортларын һәм ялгыз хуҗалыкларны мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшырудан азат итү буенча хәзерге тәртипне саклап калырга.

Үзләренең каралты тирәсе җирләренең кимендә дүрттән бер өлешенә киндер чәчкән колхозчы йортлары исә каралты тирәсе җирләренең калган дүрттән өч өлешеннән дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшырудан тулысынча азат ителәләр.

9. Дәүләткә мәҗбүри рәвештә бәрәңге тапшыру буенча бу карар белән билгеләнгән йөкләмәләрне үтәү— һәрбер колхозның, колхозчы йортының һәм ялгыз хуҗалыкның беренче чираттагы бурычы һәм ул беренче җыеп алынган бәрәңге белән үтәлергә тиеш, йөкләмәләрне үтәмәүчеләргә закон буенча җәза биреләчәк.

10. Властьның җирле органнарының һәм хәзерләү органнарының бәрәңге тапшыру буенча колхозларга, колхозчы йортларына һәм ялгыз хуҗалыкларга гектар исәбеннән булган нормадан артык йөкләмә салулары һич шиксез тыела. Дәүләткә бәрәңге тапшыру буенча йөкләмәләрне үтәгәннән соң артып калган барлык бәрәңге тулысынча колхозларның, колхозчыларның һәм ялгыз хуҗалыкчыларның үз ихтиярында кала.

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Председателе
В. МОЛОТОВ.

ВКП(б) Үзәк Комитеты Секретаре
И. СТАЛИН.

16 апрель, 1940 ел.

В. И. ЛЕНИННЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ ТУЛУ КӨНЕ АЛДЫННАН

В. И. Ленингә багышланган күргәзмәләр

Казанның Партия Мәгарифе йортында Владимир Ильич Ленингә багышланган зур күргәзмә ачылды. Күргәзмә материаллары ике зур залга урнаштырылды. Анда Ильичнең бала вактыннан алып, соңгы көннәренә кадәр булган тормышы документлар, архив материаллары, фоторәсемнәр, кульъязмалар һәм башка материаллар белән күрсәтелә. Шунда ук В. И. Ленин әсәрләреннән китап күргәзмәсе дә төзелде.

Күргәзмә һәр көнне көндезге 3 сәгаттән кичке 8 сәгаткә кадәр ачык.

***

Бөтен дөнья пролетариатының даһи юлбашчысы Владимир Ильичнең туына 70 ел тулу көненә Татарстанның Фәнни Китапханәсе күргәзмә хәзерли. Күргәзмәгә Лениннең әсәрләре һәм Владимир Ильич турындагы төрле материаллар куела.

Күргәзмәнең „РСДРП ны төзү чорында Ленин", „Ленин турында иптәш Сталин һәм аның көрәштәшләре", „Лениннең партия өчен көрәше", „Ленин 1905 нче елдагы революцияне оештыручы" һәм „Ленин Бөек Октябрь Социалистик революциясен оештыручы" дигән бүлекләре була. Күргәзмәгә шулай ук Владимир Ильич Казан университетында укыган вакытта аның турында язылган документларның һәм үз кульъязмаларының күчермәләре һәм төрле фото-рәсемнәр куела.

Мәктәпләрдә Ильич көннәре

Ленин районы мәктәпләрендә Владимир Ильич Лениннең 70 еллыгына ныклы хәзерлек алып барыла.

91 нче номерлы мәктәпнең барлык классларында В. И. Лениннең тормышы һәм революцион эше турында беседалар үткәрелә. Якын көннәрдә укучылар өчен „Ленин—Маркс—Энгельс эшен дәвам иттерүче" дигән темада лекция укылачак.

Шулай ук 37 нче номерлы мәктәптә дә Ленингә багышланган беседалар, әдәбият укулар оештырыла.

***

22 нче апрельдә 68 нче номерлы мәктәптә югары класс укучыларының В. И. Лениннең 70 еллыгына багышланган кичәләре була. Кичәдә Владимир Ильичнең тормышы һәм революцион эше турында тарих укытучысы П. Толмачев доклад белән чыга. 10 нчы класс укучысы В. Аверьянов Маяковскийның „Владимир Ильич Ленин" поэмасыннан өзекләр укыячак. 10 нчы класс укучыларыннан В. Винокурова һәм Л. Ильина иптәшләр иптәш Сталинның „Ленин турында" һәм „Лениннең үлеме уңае белән" дигән мәкаләләрен укыячаклар.

V—VII нче классларда пролетар революциянең даһие турында беседалар үткәреләчәк. 20 нче апрельдә укучылар Ленин музеййортында булачаклар.

Пехота училищесендә

Казан Пехота училищесендә В. И. Лениннең тууына 70 ел тулуга багышланган лекцияләр үткәрелде. Лекцияләр „Большевиклар партиясен төзү өчен көрәштә Ленин", „Октябрь Социалистик революциясе көннәрендә Ленин" һәм башка темаларда укылды.

Партия кабинетында һәм Ленин бүлмәсендә күргәзмәләр оештырыла. Подразделениеләрдә күп тиражлы газеталарның һәм стена газеталарының махсус номерлары чыгарыла.

23 нче апрельдә Ленинне искә алу кичәсендә үзешчәнлек сәнгате түгәрәкләре тематик концерт бирәчәкләр. Кыллы оркестр һәм хор Ленин турындагы җырларны башкарачаклар. Декламаторлар Ленин турындагы әсәрләрне хәзерлиләр.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Дингә каршы пропаганданы онытты лар

Партиябезнең тарихи XVIII нче съезды тарафыннан куелган бөек бурычларның берсен—хезмәт иясе массаларын коммунистик рухта тәрбияләү бурычын уңышлы хәл кылуда дингә каршы пропаганда эше гаять зур урын тота. Ләкин Заинский районында бу мөһим эшкә җитәрлек игтибар итмиләр.

Дөрес, ВКП(б) райкомы үзенең бюро утырышларыннан берсендә, дингә каршы пропаганда алып бару өчен махсус лекторлар да раслады. Ләкин эш шунда туктап калды. Лекторларга конкрет эш бирелмәде. Райкомның пропаганда һәм агитация бүлеге дә, шулай ук Сугышчан Алласызлар Союзының район советы да бу көчләрдән файдаланмадылар.

Райондагы партоешмалар да дингә каршы пропаганда эше белән шөгыльләнмиләр. Мәсәлән, Бассар, Иске Такмак, Шепкә авылларындагы партоешмалар бу өлкәдә берниндн дә эш алып бармыйлар. Шуңа күрә дә, дини бәйрәмнәр вактында кайбер авылларда колхоз эшенә чыкмаучылар шактый була. Поповка, Бугулда, Онбия, Иске Такмак авылларында һәм хәтта Заинскийның үзендә дә мондый хәлләрне еш очратырга туры килә.

Районда дингә каршы пропаганда эше белән шөгыльләнергә теләүче иптәшләр юк түгел. Мәсәлән, Иске Такмак авылындагы тулы булмаган урта мәктәптә һәм Заинскийдагы урта мәктәптә эшләүче иптәшләр инициативасы белән Алласызлар Союзы ячейкалары оештырылды. Район советы исә бу турыда белми дә калды.

Сугышчан Алласызлар Союзының Заинский район советы председателе иптәш Агапов районда дингә каршы пропаганда эшләренең торышы турында гомумән бер нәрсә дә белми.

— Узган ел без 6 урында лекция уздырган идек. 2 тапкыр пленум уздырылды. Ләкин пленум членнары бер нәрсә дә эшләмәделәр. Быел пленум да җыеп булмый әле. Башка эшләр турында миндә маглүматлар юк, ди иптәш Агапов.

Советның секретаре иптәш Колесов бу оешмага сайланганнан соң (1939 нчы елның июле), бер нәрсә дә эшләмәгән генә түгел, хәтта район советының делегатларын да кабул итеп алмаган. Шулай булгач, район советына сайланган башка кешеләрнең эшләре һәм гомумән оешмада учет эшләренең торышы турында сөйләп тә торасы юк. Ә Сугышчан Алласызлар Союзының Заинский район советы председателе иптәш Агаповның массалар тарафыннан үзенә йөкләтелгән эшкә җавапсыз каравын, совет һәм пленум членнарыннан бер нинди дә эш таләп итмәвен ачык итеп әйтергә кирәк.

ВКП(б) ның район комитеты бу фактлардан тиешле нәтиҗәне ясар һәм җаваплы кешеләрдән эш таләп итәр дип уйлыйбыз.

Шумушов, Исмагыйлев.

КОЛХОЗ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Әтнә районы, Киров исемендәге колхоз партия оешмасы отчет-сайлау җыелышында күрсәтелгән кимчелекләрне бетерү буенча шактый эшләр эшләде. Коммунистлар үзләренең теоретик белемнәрен күтәрү эше белән ныграк шөгыльләнә башладылар. Партия эшендә активлыклары үсте һәм партоешманың җәмагат оешмаларына һәм колхозга җитәкчелеге көчәйде. Мәсәлән, иптәш Закиров отчет-сайлау җыелышына кадәр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"ның 1 нче бүлеген генә өйрәнгән иде. Ул хәзер „Кыскача курс" ның V нче бүлеген укып конспект төзеде. Үзенең теоретик белемен күтәрүдә аеруча тырышып эшләүче иптәш Ибатуллина „Кыскача курс" ның 12 бүлеге буенча да конспект төзеде һәм аны яхшы итеп үзләштерде.

Барлык коммунистларга да партия поручениеләре бирелгән һәм поручениеләрнең үтәлеше системалы рәвештә тикшерелә. Иптәш Ибатуллина Осоавиахим оешмасына, иптәш Вәлиева комсомол оешмасына зур ярдәм күрсәтәләр. Иптәш Габитов колхоз идарәсендә эшләүчеләр арасында политик тәрбия эшләрен яхшы гына җәеп җибәрде. Колхозчылар арасында политик тәрбия эшләре көчәйтелде. Отчет-сайлау җыелышларыннан соң узган вакыт эчендә халыкара хәлләр турында һәм башка темаларда колхозчылар өчен 10 тапкыр лекция укылды, 42 тапкыр күмәк рәвештә радио тыңлау оештырылды һәм төрле темаларда 50 тапкыр беседалар үткәрелде.

Соңгы вакытта партоешма җәмагат эше алдынгыларыннан 3 иптәшне ВКП(б) членлыгына кандидат итеп кабул итте.

Соңгы вакытта колхозда производство эшләре дә күренерлек яхшырды. Язгы чәчүгә хәзерлек үз вактында тәмамланды.

З. Хөсәенев.

КОМСОМОЛ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ АКТИВЛЫГЫ ҮСӘ

Кызыл Юл районында комсомол оешмаларының эше соңгы вакытларда шактый яхшырды. ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң комсомолның район оешмасы алдынгы яшьләр хисабына 382 кешегә үсте. „Кызыл Октябрь" колхозында 18 кеше, „Комбайн" колхозында — 17, Карл Маркс исемендәге колхозда—15 кеше комсомол сафларына кабул ителде.

Комсомолецлар колхозларда җаваплы эшләр башкаралар. Комсомолец Нигмәтҗанов Гариф „Кызыл Октябрь" колхозы председателе булып, 3 комсомолец бригадир булып эшлиләр. Комсомолецлардан оештырылган махсус бригада чәчүлек орлыкларның, атларның торышын колхозлар һәм бригадалар арасында төзелгән социалистик ярыш договорларының үтәлешен тикшерде.

(ТатТАСС).



Мехкомбинатның 2 нче номерлы фабрикасында оуяу цехының зингер машинасында эшләүче стахановчы иптәш М. Латыйпов. Ул беренче квартал планын 200 процентка үтәде һәм Татарстанның XX еллыгын каршылау буенча үз өстенә алган йөкләмәсен намус белән үтәп килә.

И. Галиев фотосы.

БЕРЕНЧЕ МАЙ АЛДЫ ЯРЫШЫ

КАЗАН ТИМЕР ЮЛЫНДА

Казан тимер юлында Беренче Май алды социалистик ярышы көннән-көн киң җәелә.

Юдино станциясе работниклары поездларны тиз һәм төгәл йөртү өчен көрәшәләр. Маневр диспетчеры иптәш Кирюшин җитәкчелегендәге комсомолецлар—яшьләр сменасы ярышта алдынгы сафта бара. Бу сменаның работниклары поездларны төзүне тиз башкаралар. Поездлар төзүче иптәш Попков аеруча яхшы эшли. Шушы көннәрдә ул сменада норма буенча билгеләнгән 6 поезд төзү урынына 10 поезд төзеде. Иптәш Кирюшин пролетар бәйрәме—Беренче Майга карата социалистик Ватанга бүләккә кнагасенә һәм почет тактасына беренче булып язылды.

Юдино депосы машинистлары кривоносча эшләүнең гүзәл үрнәкләрен күрсәтәләр. Машинистлардан Плаксин һәм Тарасов иптәшләр күптән түгел генә товар поездларын Канаштан Юдинога срогыннан 2 сәгать элек алып килделәр.

Слесарь — автоматчы иптәш Строителев 10 нчы апрельдә смена заданиесен 715 процент итеп үтәде, слесарь иптәш Расков шул ук көнне 4,5 норма үтәде. Котельщиклар Бахусов һәм Сальников иптәшләр көнлек заданиене 500 процентка җиткереп үтиләр.

Беренче Май алды ярышы нәтиҗәсендә Әгерҗе бүлегенең эше дә соңгы вакытларда шактый яхшырды. Бүлектә йөк төяү буенча апрельнең беренче декада планы арттырып үтәлде. Әгерҗе депосы машинистлары арасында кривоносча поездларны йөртү хәрәкәте киң җәелә. Бу хәрәкәтнең инициаторлары Сорокин һәм Ралдигин иптәшләр кривоносча эшләүнең үрнәген күрсәтәләр.

ЛАЕКЛЫ ХӘЗЕРЛЕК

Мехкомбинатның механика заводы эшчеләре һәм инженер-техник работниклары Беренче Май бәйрәмен лаеклы рәвештә каршылау өчен социалистик ярышны киң җәелдерделәр. Бу завод Главмехпромның Москвадагы механика заводы белән ярыша. Бу ярыш договоры нигезендә мехкомбинатның механика заводы эшчеләре һәм инженер-техник работниклары 1940 нчы елның ярты еллык планын 15 нче июньгә үтәү турында йөкләмә алганнар иде. Алар бу җавапны эш белән мактаулы йөкләмәне үтәү өчен нык көрәш алып баралар.

Механика цехы стахановчысы фрезеровщик иптәш Жуков социалистик ярыш буенча алган йөкләмәсен арттырып үти. Ул көн саен нормасын 300 процент итеп үтәүгә ирешә. Сергеев, Демидов һәм башка иптәшләр нормасы ике—ике ярым тапкыр арттырып үтиләр. Алар продукциянең сыйфатын әледән-әле яхшырта баралар.

С.

Вахитов исемендәге жиркомбинат эшчеләре һәм инженер-техник работниклары Беренче Май алды ярышына кушылып, зур күтәренкелек белән эшлиләр. Ремонт-механика цехы коллективы аеруча яхшы эшли. Ул беренче квартал планын 165 процент итеп үтәде. Бу цех белән ярышучы сабын заводы апрель ае планын 25 нче числога үтәү йөкләмәсен алды.

Иптәш Баскаков тарафыннан җитәкчелек ителә торган (механика цехы) котельщиклар бригадасы апрель ае планын 200 процент итеп үтәү өчен большевикларча көрәшә. Стахановчылардан Ярочкин, Шиһапов, Александров, Калимуллин, Ткачев, Кадыйров һәм башка иптәшләр көнлек план үтәлешен 192—200 процентка җиткерәләр.

Мәслабиев.

Татхлебторг системасындагы магазиннарда социалистик ярыш договорлары яңартып төзелделәр. Сәүдә работниклары Беренче Май бәйрәмен үз эшләрендә яхшы күрсәткечләр белән каршылау өчен бердәм көрәшәләр.

6/86 нчы номерлы берләштерелгән магазин коллективы (директоры иптәш Ремизов) беренче кварталда товар әйләнеше планын 102 процент итеп үтәде һәм икенче кварталда тагын да яхшырак эшләргә ышандырды. Молотов район советы депутаты иптәш Павлухин сәүдә эшен юлга салуда зур инициатива күрсәтә, сәүдә работникларына актив рәвештә ярдәм итә.

Х. Галиев.

КУКМАРА РАЙОНЫНДА АГИТАЦИЯ-МАССА ЭШЕНЕҢ ТОРЫШЫ ТУРЫНДА

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ БЮРОСЫ КАРАРЫ

„Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларны үткәрү йомгаклары турында" ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросының 1939 нчы ел 26 нчы декабрь карарының партиянең Кукмара райкомы тарафыннан ничек үтәлүе турында ВКП(б) ның Кукмара райкомы секретаре иптәш Шульдеевның докладын тыңлап тикшергәннән соң, ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты бюросы Кукмара районындагы хезмәт ияләре арасында агитация-масса эшенең канәгатьләнерлек хәлдә түгеллеген әйтеп үтә. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар буенча сайлау кампаниясе чорында эшләгән 56 агитколлективның зур күпчелеге хәзер эшләүдән тукталган. Агитаторларның шактый өлеше үз иркенә куелган һәм беркетелгән участкыларда бер нинди дә эш алып бармый. Кукмара районының күп кенә колхозларында партиянең һәм хөкүмәтнең иң әһәмиятле карарларын колхозчыларның киң массасына җиткерү эше оештырылмаган, ә „Кызыл Тау", „Коминтерн", „Азлянь", „Большевик" колхозларында һәм башкаларда Татарстан, Чувашстан һәм Мордовия АССР лар арасындагы социалистик ярыш договоры, „Язгы чәчүгә хәзерлек турында" ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумы карары һәм партиянең XXI нче Өлкә конференциясе карары колхозчыларның гомуми җыелышларында хәзергә кадәр хәтта тикшерелмәгән дә.

ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы, язгы чәчүгә хәзерлек чорында партиянең Кукмара райкомының агитация-масса эшен йомшартканлыгын бигрәк тә гафу ителерлек түгел дип саный. Югары уңыш алу өчен стахановча көрәшүче алдынгы колхозларның һәм бригадаларның тәҗрибәсе колхозчыларның киң массасы арасында популярлаштырылмый; районның „Большевик" газетасы бу тәҗрибәне тупламый һәм язгы чәчүгә уңышлы хәзерләнүгә һәм аны уңышлы үткәрүгә массаны тупламый. Агитколлективларның һәм агитаторларның кубесенең язгы чәчү чорына эш планнары юк, ә партия райкомы хәтта районда ничә агитатор барлыкны да белми һәм аларны кыр эшләрен җәелдерү барышына туры китереп участкыларга урнаштырмаган. Шулай ук авыллардагы политик-агарту учреждениеләренең, колхоз клубларының, уку өйләренең һәм башкаларның да язгы чәчү чорына эш планнары юк.

Болар барсы да ВКП(б) ның Кукмара райкомының ВКП(б) Өлкә Комитетының 1939 нчы ел 26 нчы декабрь карарын үтәүне тәэмин итмәве, сайлау кампаниясе чорында агитация-масса эшендә ирешелгән уңышларны беркетмәве һәм политик агитациягә җитәкчелекне ачыктан-ачык йомшартуы нәтиҗәсендә килеп чыкканнар.

ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы карар бирә:

1. ВКП (б) ның Кукмара райкомын,—барлык агитколлективларны ныгыту өчен бик тизлек белән чаралар күрергә, районның хезмәт ияләре арасында агитация-масса эшен кискенлек белән көчәйтүгә ирешергә мәҗбүр итәргә.

2. Якын чорда бөтен агитация-масса эшенә нигез итеп СССР Совнаркомының һәм ВКП (б) Үзәк Комитетының авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр турындагы, колхозларның һәм ялгыз хуҗалыкларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык һәм дөге тапшырулары турындагы карарларын, СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясе карарларын, партиянең XXI нче Өлкә конференциясе карарларын һ. б. аңлатуны алырга, колхозчыларны һәм МТС эшчеләрен язгы чәчүне уңышлы үткәрүгә, социалистик терлекчелекне үстерү планын үтәүгә, социалистик ярышны һәм стахановчылык хәрәкәтен тагын да җәелдерүгә тупларга.

3. Язгы чәчү чорында бөтен агитация-масса эшенең үзәген колхоз һәм трактор бригадаларына һәм звеноларга күчерергә, һәрбер бригаданың һәм звеноның үзенә беркетелгән беседачылары һәм кычкырып укучылары булуга ирешергә.

4. Бөтен агитация-масса эшен үткәргәндә политик агитацияне хуҗалык бурычлары белән бергә бәйләп алып барырга, бригадаларда һәм звеноларда системалы рәвештә кычкырып укулар һәм беседалар үткәрергә, аларны бригаданың һәм звеноның эш нәтиҗәләре белән бик нык бергә бәйләргә, колхозчыларны һәм МТС эшчеләрен югары уңыш алу өчен көрәшнең алдынгы стахановча тәҗрибәсен үзләштерүгә тупларга.

5. Агитколлективларның һәм агитаторларның эшенә көндәлек контроль тәэмин итәргә, үткәрелә торган агитациянең эчтәлегенә игтибар бирергә, агитаторларга аларның гомуми культура һәм идея-теория дәрәҗәләрен күтәрү эшендә кирәкле ярдәмне күрсәтергә.

6. Политик-агарту учреждениеләренең (клубларның, уку өйләренең һ. б.) бөтен эшен язгы чәчү бурычларына буйсындырырга, моның өчен кинодан, радиодан, художество үзешчәнлегеннән һ. б. киң күләмдә файдаланырга.

7. Кукмара районында чыга торган „Большевик" газетасы редакторы иптәш Гаяновны,—масса арасында политик-агитациянең торышын һәм барышын газета битләрендә системалы рәвештә яктыртырга, иң яхшы агитаторларның һәм авыл хуҗалыгы стахановчыларының тәҗрибәсен киң күләмдә популярлаштырырга мәҗбүр итәргә.

8. ВКП(б) ның барлык райкомнарын,—партия райкомнары бюролары утырышында районда агитация-масса эшенең торышы турындагы мәсьәләне тикшерергә һәм аны, бигрәк тә язгы чәчү чорында көчәйтү буенча конкрет чаралар билгеләргә мәҗбүр итәргә.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты
секретаре Е. МАТВЕЕВ.

ЯҢА ЗАКОННАРНЫ ВАКТЫНДА ҺӘМ ДӨРЕС ТОРМЫШКА ҮТКӘРИК

СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясе „Халыктан доход налогы турында закон" һәм „Доход налогы салына торган халыктан торак һәм культура-көнкүреш төзелеше кирәкләренә җыем турында закон" нар кабул итте. Бу законнар халыктан доход налогы алу эшендә зур гына үзгәрешләр керттеләр.

Эшче һәм хезмәткәрләрдән доход налогы һәм культура җыемы алуда моңа кадәр кулланылган прогрессив шкала буенча айлык хезмәт хакы 140 сум булганда 0,6 процент, 600 сум һәм аннан артыграк булганда 3,3 процент күләмендә культура җыемы алына иде. Яңа закон буенча 600 сумнан югары булган хезмәт хакы да налогка прогрессив шкала белән тартыла. Шул ук вакытта 300 сумга кадәр хезмәт хакы алучыларның хезмәт хакыннан налог күләме шактый кими. Элекке вакытта эшче-хезмәткәрләрнең налогка тартылмый торган минимум хезмәт хакы төрле шәһәрләр өчен төрлечә (Казан өчен 140 сум) булса, яңа закон буенча бу минимум Союзның барлык урыннары өчен 150 сум итеп билгеләнә һәм аена 150 сумга кадәр хезмәт хакы алучылар доход налогы һәм культура җыемыннан бөтенләй азат ителәләр.

Яңа закон буенча әдәби хезмәт белән шөгыльләнүчеләрне һәм сәнгать работникларын налогка тарту системасы да үзгәртелә. Елына 20 мең сумга кадәр доход алучылар эшче-хезмәткәрләргә тиңләштереләләр. Ә 20 мең сумнан югары доход алучылар налогка моңа кадәр яшәп килгән 1 нче категория ставкаларыннан ким булган шкала белән тартылалар. Бу чара әдәби хезмәт белән шөгыльләнүчеләрнең һәм сәнгать работникларының налог түләүләрен шактый киметә. Уйлап табучыларның доходларыннан налог алу да яңа закон буенча эшче-хезмәткәрләр белән бер тигез күләмдә булачак.

Яңа закон кооперативлаштырылган һәм кооперативлаштырылмаган кустарьларның доходларын налогка тарту тәртибен дә үзгәртә. Моңа кадәр кооперативлаштырылган кустарьлар һәм һөнәрчеләр аларның мастерскойларда яки үзләренең өйләрендә махсус җиһазлар һәм станоклар белән эшләүләренә карамастан, налогка эшче-хезмәткәрләр белән бер тигез тартылалар иде. Моның өчен аларның эшләп чыгарган продукцияләрен үзләре член булып тора торган артельгә тапшырулары шарт булып тора иде. Бу практика кооперативлаштырылган кустарьларның артельнең файдасын бүлүдән ала торган һәм өйдә эшләүчеләрнең үз семья членнарының хезмәтен файдаланудан, производство калдыкларын утильләштерүдән килгән доходлары хисапка алынмый иде. Яңа закон буенча кооперативлаштырылган кустарьларның доходлары налогка эшче-хезмәткәрләрдән алына торган налог сумасыннан 10 процент арттырылып тартылалар.

Кооперативлаштырылмаган кустарьларны налогка тарту буенча да яңа тәртип кертелә. Элек кооперативлаштырылмаган кустарьлар һәм һөнәрчеләр налогка Финанс Халык Комиссариаты тарафыннан билгеләнә торган уртача доход нормалары буенча тартылалар иде. Бу норма һөнәрчеләрнең төрләре күп булу һәм районның яки шәһәрнең экономик үсеше төрлечә булуы аркасында, кустарьның фактически доходыннан артык, яки күп кенә хәлләрдә ким була иде. Яңа закон буенча кустарьларны налогка тарту аларның һәрберсенең фактически доходына карата индивидуаль рәвештә үткәреләчәк. Шуның белән бергә кустарьларга налог салу шкаласы да прогрессив рәвештә үзгәртелә.

Яңа закон буенча шәһәрләрдә эшче һәм хезмәткәрләрнең ярдәмче авыл хуҗалыгыннан килгән доходлары да налогка һәм культура җыемына тартылалар.

Үзләренең тәрбияләрендә 3 тән артык семья членнары булган эшче һәм хезмәткәрләргә налог сумасыннан 30 процент льгота бирелә.

Эшче-хезмәткәрләрдән яңа закон нигезендә доход налогы май аеның икенче яртысына хезмәт хакы биргәндә, ә культура җыемы июнь аеның беренче яртысына хезмәт хакы биргәндә тотыла башлый. Ә башка граждан-нардан налоглар 1 нче январьдан алып яңа закон буенча исәпләнәләр.

Яңа законнарны тормышка үткәрүдә финанс работникларыннан һәм предприятиеләрнең расчет бүлеге работникларыннан зур хәзерлек эшләре таләп ителә. Налог работниклары бу законнарны җентекләп өйрәнергә һәм аларны массага аңлатырга тиешләр. Шуның белән бергә, налог органнары кустарьларга 1940 нчы елга доход налогы авансын яңадан исәпләү эшенә керешергә, закон буенча налогка яңадан тартылучыларны һәм налог салу системасы үзгәргәннән соң налог сумасы артырга тиешле граждан-нарны учетка алу эшенә керешергә тиешләр. Предприятиеләрнең, учреждениеләрнең хисап работниклары үз вактында таблицалар белән тәэмин ителергә, алар белән инструктажлар үткәрелергә тиеш. Яңа законнарның дөрес үтәлүен ныклы контроль астына алып, эшче һәм хезмәткәрләргә тиешле булган льготаларның тулысынча һәм дөрес бирелүен тәэмин итәргә, комсодлар, финанс-контроль постлары, җирле Советларның депутатлары һәм алдынгы стахановчылар бу эштә налог органнарына ярдәм итәргә тиешләр.

З. Зәкиев.

Навигация алдыннан

Чистай пристане навигацияне тулы хәзерлек белән каршылый

Чистай престане коллективы 1939 нчы ел навигациясен яхшы күрсәткечләр белән төгәлләве өчен елга пароходчылыгы наркоматыннан мактау һәм бүләк алган иде. Пристань узган елны йөк төяү һәм бушату планын 115 процент итеп үтәде. 88 мең сумга экономия ясады.

Бу зур казаныш һәм урынлы мактау пристань коллективын тагын да яхшырак эшләүгә рухландырды. Бу күтәренкелек 1940 нчы ел навигациясенә большевистик хәзерлекне тәэмин итүдә хәл иткеч урын тотты. Пристань Кама пароходчылыгында беренче булып дәүләт паспортын алды.

Йөк ташу буенча клиентлардан заявкалар алу планы 11 мең 860 сумга арттырып үтәлде. Бу эштә стахановчы иптәш Шабаев аеруча зур инициатива күрсәтте. Дебаркадерларны һәм площадкаларны ремонтлауда эшләүче иптәш Засыпкин үзенә бирелгән планны 15 көн элек төгәлләде. Пассажирлар өчен көтү залы һәм кассалар, справкалар бирү бюросы, багажлар саклау камералары да яхшы сыйфатлы итеп ремонтландылар. Склад хуҗалыклары тулы тәртипкә китерелде. Пассажирлар өчен буфет, ресторан, ашханә һәм ике-өч урында киоскалар, беренче ярдәм пункты һәм балалы аналар бүлмәсе чиста, якты итеп хәзерләнделәр. Пристань тирәсе радиолаштырылды. Пассажирлар өчен ял итү бүлмәсе, күңел ачу кораллары һәм газета-журналлар белән тәэмин ителде.

Эшчеләр арасында политик-масса эшләре киң колач алды. Партияле һәм партиясез большевиклардан 8 кеше агитатор булып эшли. Иванов, Карташев, Поляков, Ваночкин иптәшләр аеруча зур тырышлык күрсәтәләр. Алар партиянең башлангыч оешмасы тарафыннан билгеләнгән план буенча халыкара хәлләр турында, партиябез һәм хөкүмәтебез карарлары турында беседалар, докладлар үткәрәләр. Шуның нәтиҗәсендә эшчеләрнең хезмәткә аңлы карашлары, политик һәм производство активлыклары әледән-әле үсә. Үткән елны навигациягә хәзерләнү чорында 48 кеше прогул ясаган булса, быел бер генә прогул да булмады.

Намуслы хезмәт белән үскән, практик эштә үзләрен таныткан алдынгы эшчеләр җитәкче эшләргә күтәреләләр. Элекке грузчик иптәш Манахов хәзер капитан булып, Малышева йөк кабул итүче һәм тапшыручы булып, Шабаев диспетчер һәм иптәш Мартынов пристань начальнигы ярдәмчесе булып эшлиләр.

Чистай пристане коллективы навигация башлануын түземсезлек белән көтә һәм аңа тулы хәзерлек белән килә.

К. Исламов.

ТАТАРСТАН БАСУЛАРЫНДА

Тракторлар эшли башлады

КАРГАЛЫ, 16 апрель. (Телефон буенча). Кызыл Армия районының күп кенә колхозлары өлгергән участкыларда сайлап чәчү эшенә керештеләр. „Марс“ колхозы 2 гектар бодай, 2 гектар солы чәчте. „Ирек“, „Активист“, Киров, Тельман, Нәриман исемендәге колхозлар да чәчүгә чыктылар.

Каргалы МТС ының „Ирек“ колхозында эшләүче 38 нче һәм 50 нче номерлы тракторлары белән бары 13—15 сантиметр тирәнлектә генә сөрүләре беленде. Бу җитешсезлекне бетерү буенча шунда ук чара күрелде. Хәзер бу тракторлар 16—18 сантиметр тирәнлектә сөрәләр. —

Гатауллин.



Казан Авыл Хуҗалыгы институты яшь белгечләр хәзерләп чыгара. Рәсемдә (сулдан уңга): институтны тәмам итеп чыгучы отличниклардан М. Кочмаркин, В. Ларионов һәм П. Буланаев иптәшләр үсемлекләр бүлмәсендә. Л. Попов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы.)

БЕРЕНЧЕ МАЙ АЛДЫ ЯРЫШЫ

Ютазы районы колхозчылары Беренче Май алды социалистик ярышын киң җәелдерәләр. Күп кенә колхозлар Беренче Май Бәйрәмен иртә культуралар чәчүне тәгәлләү белән каршыларга йөкләмә алдылар. „Балан Түбә“ һәм „Яссы Тугай“ колхозы членнары иртә культуралар чәчүне 25 нче апрельгә тәгәлләү өчен көрәшәләр. „Яссы Тугай“ колхозы стахановчыларыннан Ф. Сагдиев һәм Х. Миңлеханов иптәшләр культивацияләүдә норманы 135 процентка кадәр үтиләр. Чәчүче Әсгат иптәш Исламов көн саен һәр сошник белән 0,70 гектар урынына 1,20 гектар чәчә. Бу колхозда тырмалау эшендә күбрәк хатын-кызлар эшлиләр. Алар барсы да норманы тулысынча үтәп баралар.

Атларны яхшы тәрбиялиләр

Өмбе авлылы, „Кызыл Юл“ колхозында (Дөбъяз районы) моннан 10—15 көн генә элек күп кенә атларның хәле яхшы түгел иде. Группаларга бүлеп тәрбияли башлагач хәл бик тиз үзгәрде. Группалап тәрбиягә куйганчы уртачадан түбән көрлектә булган 22 атның 17 се хәзер уртача көрлектәләр. 3 нче бригаданың ат караучысы Фәйзи иптәш Фазылшин үзенең эше белән бик күпләргә үрнәк булырлык. Кыр эшләре башланганчыга кадәр ул үзе тәрбияли торган атларның бөтенесен дә яхшы көрлеккә җиткерү өчен көрәшә.

Ә. Хәсәнев.

*

Саба районының „Үрнәк“ колхозында атларны тәрбияләүгә нык әһәмият бирелә. Һәр атка көн саен өчәр килограмм көчле азык ашатыла. Язгы чәчү вакты өчен фураж җитәрлек хәзерләнгән.

Атлар караучы Семенова, Егорова һәм Маренова иптәшләр атларны вактында ашатуга, эчертүгә һәм чистартуга нык әһәмият бирәләр.

Никитин.

АЛДЫНГЫ БРИГАДА

ЧИСТАЙ, 17 апрель. (Телефон буенча.) Лотфулла иптәш Сибгатуллин бригадасы Чистай районы, „Мәгариф“ колхозының алдынгы бригадасы. Бригада 14 нче апрельдә өлгергән участкыларда сайлап сөрү эшенә кереште. Беренче көнне ике сабан белән 0,90 гектар эшләнде. Икенче көнне, өлгергән участкылар зуррак була башлагач, шул ук ике сабан белән 2,45 гектар (норма һәр сабанга 1,30 гектар), ә 16 нчы апрельдә инде 3,35 гектар сөрелде.

Беренче һәм икенче көннәрдә эшнең барышы турында кырда стена газетасы чыгарылды. Сайлап сөрүнең беренче һәм икенче көннәрендә Сибгатуллин бригадасының алда баруы беленде.

Бригаданың сөрүчеләреннән Шәйхеттинов, Мингалеев, Саматова һәм Хәйруллина иптәшләр норманы һәр көн 150—200 процент итеп үтәргә йөкләмә алдылар. Кырда куныл эшләү өчен кыр станы, кухня һәм җитәрлек санда продуктлар хәзерләнгән. Бригада членнары арасында масса-политик эшләре алып бару өчен 4 кеше беркетелгән.

К. Исламов.

КУЛЬТБРИГАДА

Кыр эшләрендә катнашучы колхозчыларга культура хезмәте күрсәтү өчен ВЛКСМ ның Кызыл Армия район комитеты һәм район мәгариф бүлеге 7 кешедән махсус бригада оештырдылар. Бригада „Динамо“ колхозына килеп эшкә кереште инде.

Кызлар тракторны өйрәнделәр

Әлмәт районының „Ярыш“ колхозында кызлардан 12 кеше производстводан аерылмыйча тракторны өйрәнделәр. Алар барсы да тракторчы исеме алдылар. Шулардан Мортазина, Талипова һәм Әхсәнова иптәшләр сынауны отличнога тапшырдылар.

САБАДАН СИГНАЛЛАР

(Махсус хәбәрчебездән)

Саба районы бүген-иртәгә чәчүгә чыгу алдында тора. Калкуырак җирләрдә инде чәчүгә тәмам өлгереп килә торган урыннар бар. Азин МТС ының тракторлары инде участкыларга чыктылар.

73 колхозлы бу районда чәчү орлыклары туплау эшендә яхшы гына үрнәкләр бар. 43 колхоздан үзара ярдәм тәртибендә башка колхозларга чәчү орлыклары бирү эше оештырылган. „Игенче“ колхозы башка колхозларга 270 центнер, „Биектау“ колхозы—250, „Калатау“ колхозы—260, Маркс исемендәге колхоз—271 центнер орлык биргәннәр. Нәтиҗәдә, районда колхозара ярдәмләшү тәртибендә 3.244 центнер орлык хәзерләнгән. Колхозчылар 199 центнер орлык биргәннәр. Тупланган орлыклар коры урыннарда сакланалар. Атларны тәрбияләү, чәчү инвентарьларын тулы хәзерлеккә китерү эшләре буенча „Правда“, „Яңа Тормыш“ колхозларында һәм башкаларда бик матур үрнәкләр бар.

Ләкин бу уңышлы якларга карап, җитешсезлекләрне күрмәү бик зур ялгыш булыр иде. Үлчәүгә салганда, Саба районында чәчүгә хәзерлектәге җитешсезлекләр, яхшы якларга караганда, әлбәттә, күбрәк. Районда әле чәчү орлыклары җитми торган колхозлар бар. Орлык белән үзара ярдәмләшүне тагын да киңәйтергә кирәк.

Районның кайбер колхозларында булган орлыкларны да чәчүгә яраклы итеп хәзерләү өчен пошынмыйлар. Мәсәлән, „Татарстан“ колхозында 828 центнер орлыкның 508 центнеры гына кондицияле. „Эшчән“, „Йолдыз № 2“, „Кызыл Көрәш“ колхозларында да хәл шундый ук. „Кызыл Юл“ колхозының чәчүлек солысы да, бодае да, ясмык һәм борчак орлыклары да тиешенчә чистартылып куелмаган.

Атларны язгы чәчү эшенә хәзерләүдә чиктән тыш җавапсызлык күрсәтү фактлары бар. „Йолдыз“ колхозы җитәкчеләре ат карауда үзләренә генә хас бер „тәртип“ уйлап чыгарганнар. Атлар ат караучыларга беркетелмәгән. Атларны... чиратлашып карыйлар. Ә Явлаштау авылы колхозында ат караучы Миңнебаев, Җәлалев, Рамазанов ат карарга күп вакыт малайларын җибәрәләр. „Октябрьнең 12 еллыгы“ колхозында камыт, ыңгырчак тидерелгән атлар бар. Ә ветсанитар М. Рәхмәтуллин кая йөри торгандыр, ләкин 15 әр көн буе конюшнядә күренми.

Күп кенә колхозларда атлар өчен азык хәзерләүгә әһәмият бирмәгәннәр. „Үрнәк“ колхозында ике эскерт вика шушы көнгә кадәр ташылып, хәзерләнеп куелмаган. „Якты Юл“ колхозының тупас азыклары басуда, юештә ята.

Районда: „Авыл хуҗалыгы машиналары да, транспорт инвентарьлары да нигездә хәзер“ диләр. Дөрес, бу эшне уңышлы башкарган колхозлар күп кенә. Ләкин менә Югары Утарда чәчкечләрнең ремонты бер нәрсәгә дә яраксыз, 30 агач тырманың 5 е генә хәзер. Арбаларны ремонтлау турында әле яңа гына уйлый башлаганнар.

Саба районының байтак колхозларында даими звенолар бар, ә эш юк. Килдебәк партия оешмасы секретаре Кәрим иптәш Абдуллин звенолар төзү эшенә конкрет җитәкчелек юклыктан зарлана. Ә күрсәтмәләр кай вакыт ялгыш биреләләр. Мәсәлән, районның „Колхоз Байрагы“ газетасы кар сулары тоту өчен дә махсус звенолар оештырырга кушкан. МТС тан:

— Зинһар төзәтегез бу ялгышыгызны, бөтен установкаларга каршы килә бит бу, даими звенолар үз участкыларында үзләре эшләргә тиешләр ич!—дип бик урынлы үтенеч белән редакциягә киләләр. Ләкин редакция работниклары өчен газета „абруен“ төшергәнче, ялгышлыкны төзәтми калу артыграк, күрәсең. Чөнки редакциядә бу сигналны бөтенләй ишетмәскә салышалар.

Политик-масса, тәрбия эшләрен үткәрү буенча гаҗәп бер ансат юл тапканнар. Телефон булса—бөтен нәрсә була. Теге яки бу уңай белән „укып чыгыгыз колхозчыларга, тикшерегез, өйрәнегез“ дип телефон буенча „әмер“ генә бирәләр...

Саба районында чәчүгә хәзерлек буенча картина әнә шундый.

Югарыда әйтелгәнчә, район чәчүгә чыгу алдында. Алдан ук әйтеп куярга кирәк, әгәр дә чәчүгә җитәкчелектә дә шушындый хәл кабатланса, иген уңышы өчен көрәш мәсьәләсе Саба районында җидди куркыныч астына куелачак.

Г. Хәбиб.

Партия һәм хөкүмәт карары тормышка ашырыла

Кызыл Армия районының Нәриман исемендәге колхозы членнары „Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр“ турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарын өйрәнгәннән соң, яшелчә бакчасы оештырырга карар бирделәр. Быел колхозда 2 гектар яшелчә (кәбестә, помидор, кыяр һәм суган) чәчелә.

***

Ютазы районының „Игенче“ колхозы членнары авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләүнең һәм сатып алуның яңа тәртибе турында партия һәм хөкүмәт карарын өйрәнгәннән соң, Кызыл Армия өчен яхшы атлар тәрбияләп үстерү теләге белән, нәселле ике баш бия сатып алырга карар бирделәр. „Авангард“ колхозы членнарының гомуми җыелышы колхоз правлениесенә атларның нәслен яхшырту буенча конкрет чаралар билгеләргә тәкъдим итте. (ТатТАСС).

УҖЫМ ТУКЛАНДЫРУ

Баулы районы „Новая деревня“ колхозының 3 нче бригадасы уҗым тукландыру эшенә кереште. Бригада 17 нче апрельдә 19 гектар җирдә тукландыру үткәрде. (ТатТАСС).

А. АЛИШ ӘКИЯТЛӘРЕ ТУРЫНДА

А. Алиш, барыннан да элек, балалар әдәбиятында эшләүче язучы. Аның әкиятләре үзләренең оригинальлыклары, теленең шомалыгы, тематикасының төрлелеге, реаль тормышка бик бәйләнгән булулары белән аерылып торалар, шуның өчен алар матурлар, уку өчен күңеллеләр.

А. Алиш әкиятләренең персонажларының күбесе хайваннар дөньясыннан алынган булалар. Ашыкмаучан, тупас һәм айгыра аю; хәйләкәр, ялагай һәм ике йөзле төлке; бер туктаусыз бакылдап, [illegible] сер тотмас [illegible] тырышлыгы [illegible] иптәш [illegible] кайчан [illegible] башка [illegible] ройлар [illegible] персонажлары [illegible] ра, алар [illegible] белән [illegible] торган [illegible].

А. Алиш әкиятләрендә [illegible] каршы көрәшне һәм шул көрәштә хезмәт ияләренең җиңүен чагылдыра („Капкорсак патша“ әкияте), табигать стихиясе белән көрәшү кешенең барлык киртәләрне җиңүе („Бозлар ярыла“) [illegible].

А. Алиш әкиятләренең күпчелеге халык әкиятләренә [illegible] алымнарын [illegible]. Аның [illegible] тәмамлануы [illegible] шендә [illegible] торган [illegible]. Менә „Капкорсак патша“ әкияте:

„Әүрәк-[illegible] адмирал, сәескән сотник, тәкә шутник, үрдәк урядник [illegible] патша [illegible]“.

Күрәсез,—нәк [illegible] сөйләп [illegible] ланып [illegible] Капкорсак патша [illegible] изучене [illegible] эксплоататор [illegible] атасы [illegible] тиеш [illegible] маган [illegible] не ку[illegible] кән [illegible] да, [illegible]. Ләкин [illegible] кычлы [illegible] турын[illegible] кояш [illegible] алма [illegible] күгра [illegible] җыя [illegible] бил [illegible] ташы [illegible] патша [illegible] ияле [illegible]. Патша [illegible] үз [illegible] төре[illegible] мату[illegible] идея [illegible] яулап алуларын фантастик образлар аша матур итеп гәүдәләндерүдән гыйбарәт.

Без Алиш иптәшнең бу әкиятендә чын халык әкиятләрендә генә очрый торган гадилекне, тел нәфислеген, җөмләләрнең җинаклыгын, тапкыр сайланган эпитетларның урынлы кулланылуын күрәбез.

„Кеше төсле үзе, үгезнеке төсле күзе, бүренеке кебек тешләре, нак ерткычныкы кебек булган ди кылган эшләре...“.

Автор кан эчүче Капкорсак патшаның портретын әнә шундый эпитетлар белән сурәтли. Язучы үз әкиятендәге уңай типларны да оста сайланып алынган чагыштырулар аркылы гәүдәләндерә. Монда инде безнең алдыбызга „алланып торган кояш чыгышыннан китерелгән шомырт кебек кара күзле житез егет“ килеп баса.

Алиш әкиятләрендә сүз һәм авазларның, гомумән сөйләмнең зур осталык белән оештырылган булуы, билгеле бер үлчәүдә тәртипкә салынып язылганлыгы күзгә бәрелә.

„— Кош очып җитмәслек иллләрдән, кеше аягы басмаган җирләрдән җиде диңгез үтеп, шарлавыклар кичеп минем илемә—Капкорсак патша җиренә килгән осталар остасы—Бикзирәк, минем сезгә сүзем бар әзрәк,—дип әйтте ди Капкорсак патша“.

Күрәсез, автор эчтәлекне бирү өчен матур гына сүзләр сайлап ала да, аларны билгеле бер үлчәүдә музыкаль яңгырашлы итеп тезә. Сүз һәм авазлар төзелеше оста итеп оештырылган мондый сөйләмнәр белән гына әкиятләрне балалар яратып укыйлар.

Ләкин „Капкорсак патша“ әкиятенең кимчелекләре дә юк түгел. Капкорсак патшаның кушуы буенча министрлар [illegible].

1937 нче елда язылган „Бозлар ярылды“ әкияте челюскинчеларның героик эпопеясенә, [illegible] Арктика стихиясе [illegible].

1935 нче елны язылган „Нечкәбил“ әкияте [illegible].

„Сертотмас үрдәк“ әкияте [illegible].

Алиш иптәшнең 1939 нчы ел ахрында Татгосиздат тарафыннан чыгарылган „Әкиятләр“ җыентыгында, монда искә алынганнардан башка, тагын „Кем көчле“, „Чуар тавык“, „Койрыклар“, „Бик яхшы сабак алды ябалак“, „Эт үзенә ничек хуҗа эзләгән“, „Ил төзүчеләр белән хәйлә сөючеләр“ исемендәге әкиятләре кертелгән. Болар барсы да балаларны үзләренә тартырлык итеп, җиңел һәм җинак тел белән язылганнар.

Монда тикшерелгән әкиятләр Алиш иптәшнең балалар әдәбияты өлкәсендәге эшчәнлегенең әзлекле адымнар белән үсүгә, күтәрелүгә таба баруын күрсәтәләр. Дөрес, бу әкиятләр әле художество эшләнеше ягыннан абсолют югарылыкта түгелләр. Аларда әле югарыда күрсәтелгән кебек кимчелекләр күп кенә урын алалар. Ләкин без, аеруча соңгы елларда, авторның үз иҗадындагы кимчелекләрне бетерү өстендә эшләп үсүгә, күтәрелүгә таба барганлыгын күрәбез.

Гүзәл илебездә, Сталин кояшы астында тәрбияләнүче совет балалары үз язучыларыннан тематикаларын төрләндерүләрен, зуррак темалардагы әсәрләр язуга күчүләрен, героик вакыйгаларне эченә алган реаль чынбарлык белән тыгыз бәйләнешле гыйлми фантастик жанрда яңа әкиятләр бирүләрен көтәләр. Совет балаларының бу теләкләрен үтәү юлында А. Алиш иптәш киләчәктә тагын да активрак эшләр дип ышанып калабыз.

Сәед Гариф.

Агрономия киңәшләре

Нитрагин һәм азотоген

Азот—үсемлекләр өчен иң кирәкле азыкларның берсе. Кузаклы үсемлекләрнең (борчак, ясмык, тукранбаш һ. б.) үзенчәлекләре бар: алар һавадагы азоттан турыдан-туры файдалана алалар. Кузаклы культураларның һавадагы азот белән турыдан-туры туена алулары бу культураларның гына түгел, бәлки алардан соң чәчелә торган башка культураларның да уңышын күтәрүдә гаять зур роль уйный. Чөнки кузаклы үсемлекләр туфракны азотка баетып калдыралар.

Кузаклы үсемлекләр һавадагы азотны тамырларындагы вак төерчекләрдә (бүлбечекләрдә) яшәүче бактерияләр ярдәме белән алалар. Алар „бүлбечек бактерияләр“ дип аталалар. Әгәр дә кузаклы үсемлекләрнең тамырларында бүлбечекләр булмаса, яки аз булса, алар һавадагы азоттан бөтенләй файдалана алмыйлар, яки бик аз файдаланалар. Мондый хәл, бу яки теге кузаклы үсемлек үсә торган туфракта аңа (үсемлеккә) хас булган бүлбечек бактерияләрнең булмавын, яки аз булуын күрсәтә. Ул чагында, кузаклы үсемлекләрне чәчкән вакытта аларның орлыклары белән бергә туфракка нитрагин кертелә. Нитрагин махсус завод лабораторияләрендә үрчетелеп хәзерләнгән бүлбечек бактерияләрдән тора. Барлык кузаклы культуралар өчен нитрагин куллану бездә хәзер мәҗбүри агротехника чараларының берсе булып тора.

Нитрагинның уңышны күтәрүдә зур ярдәм иткәнлеген дөресли торган фактлар бик күп. Мәсәлән, Чүпрәле районы, Чапаев исемендәге колхозда нитрагин кертү аркасында борчакның уңышы гектарга 3,04 центнер артты.

Нитрагин орлыкка чәчәсе көнне кушыла. Аның өчен бу орлык, чәчеләсе көнне, чиста такта идәнгә салына һәм орлык ничә гектар мәйданга чәчеләсе булса, шул ук мәйданга тиешле булган күләмдә нитрагин алына. Нитрагин үзенең савытыннан (банка яки шешәдән) бушатылып, башка бер чиста савытка салына һәм шунда ук аңар су өстәлә. Суны клевер, люцерна орлыклары кебек вак орлыкларның һәрбер 10 килограммына бер стакан, ә башка культураларның (борчак, вика, люпин, эспарцет һ. б.) һәрбер 30 килограммына бер стакан исәбеннән кушарга кирәк. Шуннан соң нитрагин 3—4 минут чамасы агач кашык яки калак белән болгатыла. Менә шул болганчык сыекча орлык өстенә сибелә һәм шул ук вакытта орлык агач көрәк белән болгатылып торыла.

Шул тәртиптә нитрагинлаштырылган орлык бераз гына киптерелә дә, чиста капчыкларга тутырыла һәм кичекмәстән чәчелә. Чәчеләсе орлыкларга нитрагин катнаштыруны кояш төшми торган ышык урыннарда эшләргә кирәк, чөнки кояшта бактерияләр үләләр.

Уңышны күтәрүгә, нитрагин кебек үк азотогенның да йогынтысы бик зур. Азотоген туфракта яшәүче азотобактер исемле бактерияләрдән эшләнә торган препарат. Азотобактерлар да, бүлбечек бактерияләр шикелле үк һавадагы азоттан файдаланып торалар һәм шул азотның бер өлешен алар үсемлекләргә туенырга яраклы булган формага әйләндереп туфракка бирәләр, ә туфрактан исә азотны үсемлекләр алып торалар. Азотобактерлар (бактерияләр) бүлбечек бактерияләр кебек үсемлекләрнең тамырлары эчендә түгел, бәлки тамырга бик якын урында туфракта яшиләр. Менә шуның өчен дә азотоген препараты, беренче чиратта, кузаклы булмаган үсемлекләр (бодай, солы, бәрәңге, техника культуралары, яшелчәләр, азыктамырлар һ. б.) астына кертелә. Азотобактер бактерияләре көлсу туфракта бик аз булалар, яки бөтенләй булмыйлар. Ачы туфраклар бу бактерияләргә бигрәк тә ярлы булалар. Азотоген бер гектарга 2,5 килограмм күләмендә кертелә. Чәчүгә 3—5 көн калгач 2,5 килограмм азотогенга 0,5 литр су өстәп бик яхшылап болгатыла. Суны азотогенга күләгә урында кушарга кирәк. Азотоген орлык белән шул орлык чәчеләсе көнне күләгә урында түбәндәге тәртиптә аралаштырыла: орлыклар чиста идәндә яки брезент өстенә салыналар да, һәрбер 100 килограмм орлыкка 2 литр исәбеннән су сибеп чылатыла. Шуннан соң орлык өстенә азотогенны салып агач көрәк белән бик яхшылап аралаштырырга кирәк. Азотоген катнаштырылган орлыкны кичекмәстән чәчәргә кирәк, шулай итмәгәндә азотогенның файдасы кими.

Иген уңышын күтәрүдә нитрагин һәм азотогенның көчле чара булып торуларына да карамастан, моңа кадәр кайбер җир органнары, агрономнар, колхоз җитәкчеләре бу чараларга тиешенчә игътибар бирмәделәр. Заводлардан кайтарылган нитрагин, шуның аркасында узган елларда күп кенә урыннарда тулысынча файдаланылмый калды. Мәсәлән, 1938 нче елда 5.800 гектарлык, 1939 нчы елда 5.000 гектарлык нитрагин файдаланылмыйча калды.

Быел Татарстанда 100 мең гектардан артык мәйданга (кузаклы культуралар астына) нитрагин кертелергә тиеш. Иген уңышын күтәрүдә бу кыйммәтле средстводан файдалануда үткән еллардагы җитешсезлекләрне быел һич тә кабатламаска кирәк.

Х. Шаһиев.

Татнаркомзем агрономы.

ТАШУ ВАКТЫНДА КУЯННАР

Татарстан елгаларында тоташ боз агу тәмам булды. Хәзерге көндә елгаларда су көннән-көн арта һәм болыннарга җәелә бара. Шундый ташу вактында елгалар буенда торучы җанварлар, бигрәк тә куяннар зур кыенлыкларга очрыйлар. Суның артуы сәбәпле куяннар кечкенә атауларга качалар һәм бу атаулар күмелгәч, суга батып һәлак булалар.

Соңгы елларда елга буйларындагы куяннарны коткару чаралары үткәрелә. Узган ел Татарстанда бу чаралардан зур нәтиҗә күренде. Главпушнинаның Татарстан конторасы куяннарны коткару кампаниясен быел да үткәрергә карар бирде. Моның өчен Главпушнина тарафыннан акча билгеләнде. Һәрбер коткарылган куян өчен 10 ар сум акча түләнәчәк. Бу акчаны Главпушнинаның хәзерләү пунктлары, куяннарның коткарылулары һәм су басмый торган урыннарга җибәрелүләре турында авыл советлары башкарма комитетларының белешмәләре яки актлары буенча түләячәкләр.

К. Софонов.

48 МЕҢ ЧЕБЕШ

Чистай инкубатор станциясе быел колхозлардагы фермалар һәм колхозчылар өчен „ак леггорн“ нәселле 48 мең чебеш чыгара. Хәзер инкубатор машиналарына 10 мең йомырка салынды. Апрель азагында беренче чебешләр алыначак.

„Заветы Ильича № 1“ колхозы инкубатор станциясенә үзенең кошчылык фермасыннан 10.500 йомырка бирә һәм үзенең фермасын киңәйтү өчен 2 мең баш чебеш алачак. „Дружба“, „Агрокультура“ һәм Вахитов исемендәге колхозлар да һәрберсе 500 баш чебеш сатып алу өчен договор төзеделәр. (ТатТАСС).

Чит илләрдә

НОРВЕГИЯДӘ СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 16 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгы Норвегиянең зур тимер юл узелы булган Донбос станциясе районында Германия гаскәрләренең парашют белән десант төшерүләре турында хәбәр итә.

Рейтерның Стокһольмнан алып хәбәр итүенә караганда, Германия гаскәрләре Норвегиянең күп кенә районнарында җидди җиңүләргә ирешкәннәр. Норвегиянең көньяк-көнчыгыш өлешендәге хәлгә аеруча игтибар бирелә. Швециянең „Социал-демократен" газетасы Конгсвингер районында немецләрнең кимендә 16 мең солдаты бар дип саный. Газета Норвегия гаскәрләренең ныклы каршылык күрсәтүләренә карамастан, Конгсвингерның немецләр тарафыннан алыначагы котылгысыз дип саный. Ләкин Швециянең хәрби даирәләре әгәр Германия гаскәрләре яңа өстәмәләр алмасалар үзләренең уңышларын тиз җәелдерә алмаячаклар дип исәплиләр. Германия гаскәрләренең ягулыгы, авыр артиллериясе һәм башка төрле кораллары җитешмәгәнлекне күрсәтәләр. Боларны Германиядән Норвегиягә һава юлы белән китерергә мөмкин түгел.

БЕРЛИН, 16 апрель. (ТАСС). Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Кристиансундта урнашкан немецләр батальоны кичә норвегиялеләрнең артиллерия белән коралланган 3 батальонының ныклы каршылыгына очраган. Норвегиялеләр көчләре артык булуга карамастан, кечкенә генә сугыштан соң бирелгәннәр. Алар арасында 150 офицер һәм 2 мең солдат бар.

БЕРЛИН, 16 апрель. (ТАСС). Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Швеция телеграф агентлыгының хәбәрләре буенча кичә иртә белән Швеция чиге якынында каты сугышлар булган. Германия гаскәрләре күп кенә пунктларда Швеция чигенә килеп җиткәннәр. Норвегия частьләре Швеция территориясенә чигенәләр. Монда аларны коралсызландырып интернировать итәләр.

БЕРЛИН, 16 апрель. (ТАСС). Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Ньюгорсвольд хөкүмәте һәм Норвегия армиясенең командованиесе Ослодан төньяктарак Германия гаскәрләренә каршы көрәшне дәвам иттерәләр. Норвегиянең короле Гаакон Норвегия гаскәрләре белән берлектә бара.

ЛОНДОН, 16 апрель. (ТАСС) Рейтерның Стокһольмнан алып хәбәр итүенә караганда, Германия гаскәрләре хәзерге вакытта Норвегиянең Тронгеймнан 20 миль көнчыгыштарак булган Хегра фортларына атака ясыйлар. Норвегия гаскәрләре Германия гаскәрләренең хәрәкәт итүләренә тоткарлык ясау теләге белән юлларга киселгән агачлардан киртәләр куялар.

НЬЮ-ЙОРК, 16 апрель. (ТАСС). Юнайтед Пресснын хәбәр итүенә караганда, кичә төнлә каты сугыштан соң Норвегия гаскәрләре Конгсвингер шәһәрен ташлап чыкканнар.

ГЕРМАНИЯ ИНФОРМАЦИЯ БЮРОСЫНЫҢ ЮККА ЧЫГАРУЫ

БЕРЛИН, 16 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының Ослодан алып хәбәр итүенә караганда, Норвегия яр буеның аерым пунктларында англичаннарның десант төшерүләре турында англичаннар тарафыннан таратыла торган хәбәрләр уңае белән монда Германия гаскәрләре алган бер генә пунктта да бер генә англичан солдатының да юклыгын хәбәр итәләр. Бюроның хәбәрендә Осло районында Германия гаскәрләренең планлы төстә хәрәкәт итүләре нәтиҗәсендә бу территориянең Норвегия гаскәрләреннән тулысынча чистартылганлыгы күрсәтелә. Инде хәбәр ителгәнчә, аларның зур өлеше Швеция чиген үтеп чыккан.

Германия армиясе верховный командованиесенең сводкасы

БЕРЛИН, 16 апрель. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе хәбәр итә: „15 нче апрельдә Германия гаскәрләре алган бер генә пунктта да англичаннар десант төшерергә матушмадылар. 15 нче апрельдә көндез англичаннар Нарвикка һавадан һөҗүм ясарга маташтылар, ләкин бу эш барып чыкмады. Нарвик янында Англиянең зур гына хәрби диңгез көчләренең хәрәкәте сизелде. Германиянең хәрби диңгез көчләре Тронгеймда, Бергенда һәм Ставангерда портларны ныгытуны дәвам иттерделәр. Алар яр буен саклауны көчәйттеләр. Германия су асты көймәләренең хәрәкәте дошман су асты көймәләренең операцияләрен чикләде. Германия авиациясе Төньяк диңгез өстендә һәм Норвегиянең төньяк яры өстендә Нарвикка кадәр разведка очышлары үткәрде. Гельголандтан төньяк-көнчыгыштарак һава сугышында Германия бухтасы өстеннән үтәргә маташкан һәм бомбалар ташлаган Англия самолеты бәреп төшерелде, ләкин бомбалар тиешле җиргә тимәде. Скагеррак бугазында англичаннарның икенче бер самолеты бәреп төшерелде. Германиянең бер самолеты үз базасына кайтмады.

15 нче апрельдә Норвегия ярлары тирәсендә булган Англия крейсерына Германия самолетлары һөҗүм итеп зур зыян китерделәр һәм ул озаклямый батты. Моннардан тыш „Сандерлэнд" типындагы оча торган көймә юк ителде".

БЕРЛИНДӘ ЧИТ ИЛ МАТБУГАТЫ ВӘКИЛЛӘРЕНЕҢ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

БЕРЛИН, 16 апрель. (ТАСС). Бүген Германиянең чит ил эшләре министрлегендә чит ил матбугаты вәкилләре конференциясендә Норвегиядәге хәл турында белдерделәр. Норвегиянең Германия гаскәрләре алган территориясендә Норвегия верховный суды председателе Кристенсен житәкчелегендә яңа хөкүмәт төзелде. Аның бары тик башкару функцияләре генә бар. Германия даирәләре яңа хөкүмәтне конституция нигезендә төзелгән дип күрсәтәләр, чөнки Норвегия конституциясендә верховный суд председателенең аерым хәлләрдә илне идарә итүне үз өстенә ала алуы турында күрсәтмә бар. Журналистлар даирәләрендә Норвегия конституциясе буенча верховный суд председателе бу функцияләрне бары тик король үлгән хәлдә генә үз өстенә ала ала дип белдерделәр. Яңа хөкүмәтнең дәүләт киңәшчесе—Квислинг. Аның төп функциясе Норвегия армиясен коралсызландырудан һәм таратудан гыйбарәт.

Журналистларның Берлиндәге Норвегия илчесе кайсы хөкүмәтнең илчесе булачак дигән сорауларына „Норвегиянең иске хөкүмәте асылда хәзер яшәми, ә яңа хөкүмәте исә асылда Норвегиянең бердәнбер хөкүмәте булып тора һәм шунлыктан Норвегиянең Берлиндәге илчесе яңа хөкүмәт вәкиле булырга тиеш" дигән җавап бирелде.

Конференциядә Германиянең авторитетлы вәкилләреннән берсе Норвегия территориясендә хәзер гомумән Норвегиянең короле һәм аның хөкүмәте юк инде дигән фикерне әйтте. Корольнең кайда икәнлеге билгеле түгел.

ФАРЕР АТАУЛАРЫН АНГЛИЯ ГАСКӘРЛӘРЕ ОККУПАЦИЯЛӘҮ

ЛОНДОН, 16 апрель. (ТАСС). Рейтерның хәбәр итүенә караганда, бүген түбәнге палатада чит ил эшләре министренең урынбасары Батлер Англия гаскәрләренең Фарер атауларына төшкәнлеген белдергән. Батлерның сүзләренә караганда, атауларның губернаторы оккупациягә ризалык биргән.

Рузвельтның рече

НЬЮ-ЙОРК, 16 апрель. (ТАСС). Пан-Америка союзы комитетының утырышында Рузвельт речь сөйләде. Ул „көнбатыш ярым шарда тынычлыкны теләү белән генә тынычлыкка ирешергә мөмкин түгел. Тынычлыкны саклау өчен сүздән зуррак нәрсәләр кирәк" диде. Аннары Рузвельт „әгәр көрәшкә чакырганда без көчкә көч белән җавап бирергә хәзер булсак" без тыныч юл белән бара алырбыз диде.

Аннары Рузвельт Америка илләренә әле сугыш кагылмаса да, „иске дөньяда бара торган вакыйгаләр яңа дөньядагы тынычлыкта турыдан-туры һәм тирән чагылалар" диде. Рузвельт шунлыктан „без үзебезгә һәрбер мөмкинлекләрне каршы алырга ирек бирә торган чаралар юлына бастык" дип белдерде. Рузвельт „океанның теге ягыннан турыдан-туры яки читләтә булган теләсә нинди атакаларны Америка илләренең һәр кайсының абсолют бөтенлеген бергәләп яклау һәм саклау буенча" Америка илләренең карарларын һәм сугыш Америкага кагылмасын өчен Панамада юллар һәм методлар хәзерләнгәнлекне искә алып үтте. Рузвельт болай диде: „Мин безгә артык нәрсә кирәк түгел дип уйлыйм, ләкин әгәр кирәк булса мин үзебезнең тырышлыкларыбызның тулысынча уңышка ирешәчәгенә ышанам".

СТАВАНГЕРНЫ БОМБАГА ТОТУ

БЕРЛИН, 17 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Англия самолетлары 16 нчы апрельгә каршы төндә Ставангер шәһәренә һәм аның тирәсендәге аэродромга яндыра торган һәм нык шартлый торган күп кенә бомбалар ташлаганнар. Бомбалар байтак кына йортларга төшкәннәр, шуның нәтиҗәсендә тыныч халыктан берничә кеше үтерелгән. Бомбаларның берсе аэродромда Норвегиянең иске үрнәктәге ике самолетын һәлак иткән.

АНГЛИЯ ЭСМИНЕЦЛАРЫНЫҢ НАРВИККА АТУЛАРЫ

БЕРЛИН, 17 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының тапшыруына караганда, кичә Англия эсминецлары Нарвик портына атканнар. Ләкин Германия артиллериясе тарафыннан көчле ату белән җавап бирелгәнлектән, англичаннар бу районда төшәргә омтылмаганнар.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ҮЗӘК КЫТАЙДА. Цзянси провинциясенең төньяк өлешендә Наньчаннан төньяк-көнбатыштарак Ань-и секторында каты сугышлар бара. Бу районда кытай частьләре берничә пунктны алдылар.

Хубэй провинциясенең көнчыгыш өлешендә соңгы көннәрдә Ханькоудан төньяк-көнчыгыштарак Синьчжоу якынында каты сугышлар булды. Кытайлар японнарның атакаларын кире кактылар.

Кытай гаскәрләре Чжэцзян провинциясендә Хайянь шәһәренә бәреп кереп, электр станциясен һәм сугыш кирәк-яраклары складларын җимерделәр. Шуннан соң алар элекке позицияләренә чигенделәр.

15 нче апрельдә Шанхайдан 30 километр ераклыкта Шанхай—Цинпу шоссе юлында 1.500 кешелек кытай партизаннары японнарга каршы сугыштылар. Ике як та зур югалтуларга дучар булды.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА. Шаньси провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә Чжанцзы тирәләрендә сугышлар дәвам итә.

Хэбэй провинциясендә 11 нче апрельдә кытайлар отряды Бэйпиннән көньяктарак Синьчэн янында японнарның позицияләренә атака ясадылар.

КӨНЬЯК КЫТАЙДА. Кантоннан көньяк-көнбатыштарак япон гаскәрләре Синьхой—Хэшань шоссе юлында активлыкларын көчәйттеләр. 11 нче апрельдә японнар Синьхойдан 30 километр көньяктарак булган Куцинга ныклы һөҗүм башладылар. Кытайлар ныклы каршылык күрсәттеләр, японнар чигенергә мәҗбүр булдылар.

Миша Бобров „үзенең машинасында" прогулкада. В. Лужбин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

БЕРЕНЧЕ МАЙГА ХӘЗЕРЛЕК

ПОЖАР КОМАНДАЛАРЫНДА

Халыкара пролетариат бәйрәме Беренче Майга хәзерлек уңае белән Казандагы пожар командаларында ярыш договорларының үтәлешен тикшерү һәм яңа договорлар төзү башланды. Пожар охранасы работниклары оборона эшләрен тагын да көчәйтү һәм пожар сүндерү техникасын яхшы үзләштерү өчен көрәшәләр. [illegible]

Беренче Май демонстрациясендә пожар охранасы работникларының махсус колонна тезелә. Алар үзләренең оркестрлары белән чыгачаклар.

Бөтен шәһәр күләмендә костер

Казан Пионерлар йортында Беренче Майга карата балаларның үзешчәнлек сәнгате олимпиадасы башланды. 18 нче, 23, 24 һәм 29 нчы апрельдә олимпиаданың дәвамы була.

30 нчы апрельдә Пионерлар йортында Беренче Майны каршылау кичәсе булачак, бөтен шәһәр күләмендә зур костер ясалачак. Костерга уку отличникларыннан 400 кеше чакырылачак.

Бәйрәмне лаеклы рәвештә каршылауга хәзерләнәләр

Казан Авыл Хуҗалыгы институтының җәмагать оешмалары Беренче Май бәйрәменә лаеклы хәзерлек алып баралар. Комсоргларның, профоргларның һәм агитаторларның инструктив кәңәшмәләре үткәрелде, студентларның группа җыелышлары булды, аларда [illegible]

Доцентлардан Курамшин, Хәйруллин, аспирантлардан Мамаев, Чхендзе һәм коллективның работникларыннан Сәгыйтова, Азимова [illegible] Беренче Майга кадәр ПВХО значокларына нормалар тапшырырга йөкләмә алдылар. [illegible]

Беренче Май алдыннан институтта Беренче Май алды ярышы нәтиҗәләренә йомгак ясалачак һәм алдынгылар бүләкләнәчәк. (ТатТАСС).

РАЙОНДА КАРБЫЗ ЧӘЧҮ

Быел Алабуга районында беренче тапкыр буларак „Красный Партизан" колхозында бер гектар мәйданга карбыз чәчелә. Моның өчен 28 парник рамы хәзерләнде һәм 3 килограмм орлык алынды.

Карбыз чәчү, аны тәрбияләү тәртибен өйрәнү өчен колхозда 5 кешедән түгәрәк оештырылды.

Яңа йортлар

Шушы елның апрель башларында Серго исемендәге завод эшчеләре өчен 6 катлы, 18 квартиралы таш йорт салынып бетте. Йорт хәзер эксплоатациягә бирелде. Шулай ук ике катлы агач йорт та салынып бетеп эксплоатациягә бирелде. Беренче Май бәйрәменә 3 катлы тагын бер таш йорт салынып бетәчәк.

Авылларга врачлар җибәрү

Татарстан Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариаты язгы чәчү вакытында колхозчыларга медицина ярдәме күрсәтүне көчәйтү өчен 30 врач җибәрергә карар бирде. [illegible] Алар район больницаларында һәм амбулаторияләрдә эшләячәкләр. [illegible]

Тракторчы хатын-кызлар

Татарстан МТС ларында производстводан аерылмыйча хатын-кызлардан тракторчылар хәзерләү курслары оештырылган иде. Курсларга барлыгы 2.474 кеше тартылды. Шулардан 635 кеше курсларны уңышлы итеп чыкты. Беренче Май бәйрәменә курсларның күбесендә укулар тәмам була. Яңа хәзерләнгән хатын-кыз тракторчыларның 450 се тракторларга беркетелде инде. Хәзерге көндә Татарстан МТС ларында эшләүче тракторчы хатын-кызларның саны 800 дән арта. Алардан 14 е трактор бригадаларының бригадирлары булып эшлиләр.

ИНСТРУМЕНТАЛЬ ЗАВОДНЫ КИҢӘЙТҮ

Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты Профсоюз урамындагы инструменталь заводны киңәйтергә карар бирде. Бу завод Киров урамындагы 12 нче йортка күчерелә. Анда капитальный ремонт ясала һәм яңа станоклар салына. Заводны киңәйтү өчен 300 мең сум акча җибәрелде.

Инструменталь заводта быел халык товарлары җитештерү шактый арта. Анда 3.500 кровать, 71 мең чиләк, төрле савыт-сабалар, примус горелкалары һәм башкалар эшләнәчәк.

ТАТАРСТАНДА

Росскультторгның 4 нче магазины язгы ау һәм балык тоту сезоны өчен 100 мең сумлык товар хәзерләде. Алар арасында аучылык өчен төрле кораллар, җәтмәләр, сөрәкәләр һәм башкалар бар.

Татарстан колхозларында үлән, житен, киндер, көнбагыш һәм кок-сагыз чәчү мәйданын киңәйтү өчен быел Авыл Хуҗалыгы банкысыннан 460 мең сум кредит җибәрелә.

Быел Казан Юридик институты һәм хокук мәктәбе укучыларын ял йортларына, курортларга җибәрү өчен 65 путевка бирелә. Узган ел 62 путевка бирелгән иде.

Осоавиахимның Алабуга район советының ПВХО инструкторлары хәзерләү курсы 1940 нчы елда ике чыгарыш ясады. Хәзер бу курста 19 кеше укый.

Советлар Союзы шәһәрләре буенча. Рәсемдә: Белосток шәһәренең Совет урамы.

Д. Чернов фотосы (ТАСС фото-клишесе).

ЕЛГАЛАРДА

Волга суы 17 нче апрельгә каршы бер тәүлек эчендә Горький янында 32 сантиметр, Вязовые янында 73 сантиметр, Югары Ослан янында 71 сантиметр артты. Югары Ослан янында арткан бөтен суның биеклеге 6 метр 9 сантиметр булды. Горький, Вязовые һәм Кама Тамагы янында боз ага.

Волганың түбән агымы навигациягә ачылды. Нефть баржалары таккан буксир пароходлар Астраханнан Сталинградка килеп җиттеләр. Аларның кайберләре Саратовка менеп җиттеләр.

Кама суы Алабуга янында 29 сантиметр, Сокольи янында 39 сантиметр, Лаеш янында 37 сантиметр артты. Сокольи һәм Лаеш янында сирәк боз агып тора.

Вятка суы Вятские Поляны янында 124 сантиметр, Мамадыш янында 59 сантиметр артты. Бу пунктларда боз ага.

Ока суы Кашира янында 87 сантиметр, Муром янында 39 сантиметр артты. Кашира янында [illegible] боз агып бетте. Муром белән Горький арасында боз агу дәвам итә.

Гыйлми дәрәҗәләр бирү

Казан шәһәренең Ветеринария институты гыйлми советы 1939 нчы елны доктор һәм фәннәр кандидаты дәрәҗәсен бирү буенча 41 кешенең хезмәтләрен карады.

38 фәнни работникка гыйлми дәрәҗә бирелде. Шул исәптән 14 кеше фәннәр доктор исмен, 24 кеше фәннәр кандидаты исмен алды.

1939 нчы елны Ветеринария институтының 12 фәнни работнигы диссертация яклады. Диссертация яклау өчен Алматадан—3, Чкаловтан — 3, Киевтән — 2, Кировтан—2, Омскидан—3, Сәмәркандтән—2, Ереванидан—1 кеше килде. Башка урыннардан да килүчеләр булды.

БЕЛДЕРҮ

20 нче апрель, иртәнге 8 сәгатьтә ВКП(б) ның Өлкә һәм Шәһәр Комитетларының Партия Мәгарифе йортында, партиянең шәһәр активы өчен, лектор иптәш Фирсов тарафыннан, „Ленин Казанда" дигән темада лекция укыла.

ВКП (б) ның Казан Шәһәр Комитеты.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

ПОЖАР ОХРАНАСЫНЫҢ 22 ЕЛЛЫГЫ

Моннан 22 ел элек Совет хөкүмәте пожар охранасын оештыру турында декрет чыгарды. Яш Совет дәүләтенең социалистик милкен саклау өчен янгынга каршы чараларның яңа методлары кирәк иде.

Ут—кешенең дусты да, дошманы да. Аның дуслыгын исбат итеп торасы юк, ләкин утның бик куркынычлы дошман булуы турында бераз сөйләргә кирәк.

Без утка һәм аның белән эш итүгә гадәтләнгәнбез. Шунлыктан еш кына аның белән эш иткәндә бик ышанып һәм җавапсыз эш итәбез. Пожардан саклану чараларын халык әле һаман да начар үти. Ут чыгарга мөмкин булган нәрсәләргә һәм утның үзенә саклык белән карарга кирәклекне оныталар. Дөрес, ут төртүдән пожар чыккан вакытлар да була, ләкин гадәттә пожарлар утка саксыз караудан чыгалар. Шунлыктан, халык мәкалендәгечә, кайчандыр Москваның януына сәбәп булган „бер тиенлек шәм" турында бер вакытта да онытмаска кирәк.

„Пожар турында шалтыратырга" дигән сүзләр язылган 11 һәм 15 нче номерларны кем генә белми! Элемтә начар булган заманнардан калган „каланча" күптән бетте инде. Шәһәр каланчаларында ялтыравыклы каска кигән кешене таба алмассыз. Хәзер пожар турында телефон аркылы хәбәр ителә. Казанның Чернышевский урамында пожар охранасының үзәк шәһәр станциясе бар. Анда дежурный телефонистка утыра. Аның алдында пожар булган урынга бару өчен путевкалар бланклары һәм ике башы да очланган карандаш ята. Пожар турында хәбәр алынгач, шәһәр пожар командасының дежурный телефонисткасы тревога бирә һәм пожар чыккан урынга бару өчен путевка яза. 18—20 секундтан машиналар гараждан чыгып китәләр...

Пожар охранасы работниклары арасында 29 еллык стажлы В. Д. Голубев, 26 еллык стажлы Гоголев һәм гаять зур геройлык күрсәтүче Нәҗмиев иптәшләр кебек, күп хезмәт күрсәткән кешеләр бар. Голубев һәм Нәҗмиев иптәшләр грамоталар һәм почет билгеләре белән бүләкләнделәр.

Казанда пожар охранасы буенча яңа кадрлар да үсә. Урта команда составы хәзерләү өчен пожар сүндерү техникасы мәктәбе, шулай ук кече начальниклар составы хәзерләү өчен курслар эшләп киләләр.

Пожар охранасы работниклары арасында системалы рәвештә культура-агарту эше алып барыла. Түгәрәкләр, политик уку, командирлык белеме һәм гомуми белем алу оештырылды.

22 еллык көнендә пожар охранасы работникларына дәүләтебезнең социалистик милкен, шулай ук хезмәт ияләренең милекләрен саклау өчен көрәш фронтында тагын да зуррак уңышларга ирешүләрен телибез.

Соколов.

СССР Госпланы Халык Хуҗалыгы Учеты Үзәк Идарәсенең
УКЫТУ КОМБИНАТЫ
производстводан аерып укытып, киләчәктә Ленин районы территориясендәге заводта эшләү өчен Казанда
ХИСАПЧЫЛАР ХӘЗЕРЛӘҮ КУРСЛАРЫ АЧА
Курсларда укучыларга, аларның академик өлгерешләренә карап, айга 150 сумнан 225 сумга кадәр күләмендә стипендия бирелә. Уку срогы алты ай.
Курсларга 17 дән 25 кә кадәр яштәге, кимендә 7 класс күләмендә белемле һәм Казанда даими тору урны булган кешеләр алыналар.
Гаризалар Укыту комбинаты канцеляриясендә һәр көн иртән 9 сәгатьтән көндез 3 кә кадәр алына. Казан, Чернышевский урамы 11. 621—1

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген яңа программа буенча
ЗУР ЦИРК УЕНЫ
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
ЯРЫШЫ ДӘВАМ ИТӘ
ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ
Бүген, 18 нче апрельдә
ЗУР ПРОГРАММАДА
КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ
Уеннар: көндез 12 дә, кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 18 нче апрельдә көндез һәм кич
ТАНЯ
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 8 сәгатьтә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

Подписчиклар игтибарына!
МЕДИЦИНА ЖУРНАЛЛАРЫНА
ТӨРЛЕ СРОКЛАРГА
ПОДПИСКА АЛУ
ДӘВАМ ИТӘ
1940 нчы елның 1 нче январеннан башлап, журналларның барлык номерларын алдыру өчен подпискалар шушы ел, 20 нче апрельгә кадәр алына.
ПОДПИСКАЛАР гомуми ял көннәреннән башка, һәр көн иртән 8 сәгат 30 минуттан көндезге 4 кә кадәр Союзпечатьнең Шәһәр бюросында (Чернышевский урамы, 8) һәм Елга аръягында 32 нче, Плэтәндә 22 нче, Карл Маркс урамында 15 нче һәм Ленин районында 36 нчы
почта бүлекләрендә алына
652—1 „Союзпечать".

28 нче апрель, кич 7 сәгатьтә Терапевтика клиникасы факультеты аудиториясендә, Казан Дәүләт Мединституты гыйлми советының ачык утырышы чакырыла һәм түбәндәге темаларда халык алдында
ДИССЕРТАЦИЯ
яклау үткәрелә:
1. Медицина фәннәре докторы дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен, врач П. М. Старков. Тема: „Азот закисе һәм циклопропан белән газ наркозы".
Рәсми оппонентлар: профессор Б. Г. Герцберг, А. В. Кибяков һәм Н. А. Михеев.
2. Медицина фәннәре кандидаты дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен, врач И. Н. Комаров. Тема: [illegible]
Рәсми оппонентлар: профессор А. Д. Адо һәм доцент Н. И. Гольдштейн.
Диссертация материаллары белән [illegible] китапханәсендә танышырга мөмкин.
650—1 Дирекция.

Казан Дәүләт Педагогия институтына даими эшкә БУХГАЛТЕР, БУХГАЛТЕР ЯРДӘМЧЕСЕ һәм ХИСАПЧЫЛАР кирәк. 622—3—2

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 18 нче апрельдә көндез
МАСКАРАД
кич—ПРЕМЬЕРА
МЕТЕЛЬ
20 нче апрельдә
КУРКЫНЫЧЛЫ СУД
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
19 һәм 25 нче апрельдә Зур театр бинасында
ФАУСТ
21 нче апрельдә
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ
Кич 8 сәгатьтә башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 10-30, 12, 2, 4, 5-30, 7, 8-30, 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм АРИНКА
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	МОРЯКЛАР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8, 10 да.	12, 2 һәм 4 сәгатьтә ТИРӘН РЕЙД Кичке сеансларда ТАШЛАНДЫК
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	ГРОЗА
„ПИОНЕР" [illegible]	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„Колхозник" 6, 8, 10 да.	ШӘХСИ ЭШ
„РОТ-ФРОНТ" 6, 8 һәм 10 да.	ЯҢА ЗАМАННАР
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1525. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1477.